Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Урдалы гомуми төп белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе

“Каралды”- Урдалы гомуми төп белем бирү мәктәбе методик берләшмә утырышы.
МБ житәкчесе:
Миндиярова Х.М
Беркетмә №1,
26 нчы август 2021 нче ел

“Килешенде”- Урдалы гомуми төп белем бирү мәктәбенең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары:
Атыпова И.Р.
26 нчы август 2021 нче ел

«Раслыйм»- Урдалы гомуми төп белем бирү мәктәбе директоры:
Г.Р.Зайнутдинова
Приказ № 100
26 нчы август 2021 нче ел

**Өстәмә гомумбелем бирү программасы**

**«Яшь ижатчы»**

Яшь категориясе: 12-15 яшь

Тормышка ашыру вакыты – 1 ел

Программаны төзүче:
өстәмә белем бирү педагогы
Бурганова Гөлназ Тагировна

2021

Туктар - Урдаласы

## Аңлатма язуы.

Замана мәгариф системасы алдына гаять мөһим яңа бурычлар куйды. Мәктәп укучыларның алдагы тормышы һәм язмышы турында уйланырга, урындагы шартларны истә тотып, аларны тормышка әзерләүнең иң кулай юлын табарга тиеш.

Түгәрәк эшчәнлегендә укучыларда бәйләнешле сөйләм үстерү юнәлеше чагылыш таба. Хәзер кешенең рухи дөньясы фикерле белүе беренче планга чыга. Шуңа күрә иң кирәкле сыйфат - үз фикереңне эзлекле, дәлилләп, сурәтләп әйтә белү, бәхәстә катнаша алу.

“Яшь иҗатчы” түгәрәге укучыларның иҗади сәләтләрен үстерүгә багышлана. Бу түгәрәк стена газеталарына, балалар матбугатына, “Заман сулышы”район газетасына язышып торучы яшь хәбәрчеләр, сәхнәләрдә актив чыгыш ясаучы үзешчәннәр тәрбияләүне күз алдында тота..

“Яшь иҗатчы” түгәрәге укучыларны татар әдәби теленә игътибарлы һәм сак булырга өйрәтә, һәр сүзнең мәгънәсен белеп, урынлы һәм дөрес кулллануның ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуын төшендерә. Шулай ук аларны күзәтүчән, аралашучан һәм җор телле булырга булыша, җаваплылыкны арттыра, сәхнәдә үз-үзеңне тоту культурасы тәрбияләргә ярдәм итә.

Әлеге түгәрәктә алган күнекмәләр сочинение һәм изложение язганда җиңеллек китерә, балаларның сөйләм телен үстерергә зур этәргеч булып тора.

Түгәрәкнең **максаты**: укучыларның сәләтләрен ачыклау, аларның иҗади эшчәнлегенә кирәкле шартлар тудырып, талантын үстерү

Түгәрәкнең максатына ирешү өчен, түбәндәге **бурычлар** куела:

-укучыларны кызыксынучан булырга һәм күзәтә белергә өйрәтү;
-туган телгә хөрмәт тәрбияләү;
-уй-фикерләрен дөрес итеп һәм логик эзлеклелектә язарга өйрәтү;
-татар теленең әйтем-мәкальләрен, фразеологик әйтелмәләрен урынлы куллана белү серләренә төшендерү;
-тема таба белү, фактлар туплау, әңгәмә үткәрү, текст төзү, татар матбугаты тарихы турында башлангыч мәгълүмат бирү;
-язган материалларны матбугат чараларында бастыру;
-укучыларның грамоталы яза белү күнекмәләрен камилләштерү;
-татар халкының милли традицияләренә мәхәббәт тәрбияләү;
-авыл клубларында чыгыш ясау, сәхнәләштерелгән тамашалар күрсәтү.

Түгәрәк эше расписаниедә күрсәтелгән вакыт белән генә чикләнми. Укучыларның язма эшләре көн саен тикшерелә, анализлана, төзәтмәләр кертелә. Һәр балага аерым якын килеп, индивидуаль һәм дифференциаль эш алып барыла.

Түгәрәк эше расписание буенча җомга көнендә 1,5 сәгать үткәрелә.

### Көтелгән нәтиҗәләр

Программа материалын уңышлы үзләштергән укучы түбәндәге белем һәм күнекмәләргә ия булырга тиеш:

- ✓ изге сүздән образ тудыра, аны сәнгатьчә зәвык белән эшли, художестволы чаралар ярдәмендә тамашачыларга җиткерә белә;
- ✓ Татарстан, татар халкы, аның тормыш-көнкүреше, традицияләре, әдәбияты, сәнгате турында әдәби телдә сөйли һәм яза белергә;
- ✓ үз милләтенең культурасы, сәнгате һәм әдәбияты белән горурлану хисләре кичерә белергә,
- ✓ текстны камилләштерергә, кабатлауларны булдырмыйча сүзләрне синонимнары белән алмаштырырга;
- ✓ фәнни-теоретик материаллар һәм төрле чыганаклар белән мөстәкыйль файдалана алырга;
- ✓ сөйләм культурасы таләпләрен үтәргә;
- ✓ өйрәнелгән темалар буенча стандарт булмаган биремнәрне үтәргә;
- ✓ чит тирәлектә үзеңне иркен тотарга.

### Программаның эчтәлеге

- ➢ Фонетика, морфология, синтаксис бүлекләренә караган катлаулы олимпиада биремн. үтәү;
- ➢ Укучыларның фикерләү сәләтен үстерү максатыннан иҗади эшләр эшләү:
  аваз үзгәрешләренә мисаллар булырлык итеп, төрле темаларга шигырь яки хикәя язу;
- ➢ Төрле конкурс, конференцияләрдә катнашу;

- Газета чыгару, иҗади диктант язу;
- Район, республика олимпиадасына, фәнни-гамәли конференциягә әзерләнү;
- Авыл китапханәсенә экскурсияләр оештыру.

**Календарь – тематик план**

| Тема | Сәг. саны | Шулардан | | План б.ча дата | Фак тик дата | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Теория | Гамәли эш | | | |
| Кереш утырыш. Эш планы белән таныштыру. | 1,5 | 1,5 | | | | |
| “Татарча диктант”акциясендә катнашуга чакыру, әзерлек | 1,5 | | 1,5 | 1.09 | | |
| “Туган авылым !” Туган ягыбызның гүзәллеге турында иҗат ителгән шигырь, язмалар уку, шушы темага иҗат эше. | 1,5 | 1,5 | | 8.09 | | |
| “Көз”, “Укытучы” темасына шигырьләр иҗат итү, иншалар язу. | 1,5 | | 1,5 | 15.09 | | |
| Бергәләп язмаларны тикшерү | 1,5 | 1,5 | | 22.09 | | |
| “Көмеш кыңгырау” газетасына күзәтү ясау | 1,5 | | 1,5 | 29.09 | | |
| Рифмалауга күнегүләр башкару. | 1,5 | | 1,5 | 6.10 | | |
| Олимпиадага әзерләнү (мәктәп туры) | 1,5 | | 1,5 | 13.10 | | |
| Грамматик биремнәрдән уен-викторина. | 1,5 | | 1,5 | 20.10 | | |
| Аралашу күнекмәләрен тикшерү – тренинг. | 1,5 | | 1,5 | 27.10 | | |
| “Сабантуй” газетасында басылган шигырьләр,мәкаләләрне күзәтү | 1,5 | | 1,5 | 3.11 | | |
| Авыл китапханәсенә экскурсия. | 1,5 | | 1,5 | 10.11 | | |
| Матур әдәби китапларны тәкъдир итү | 1,5 | 1,5 | | 17.11 | | |
| “Әниләр – тормышның яме!” – әдәби кичә | 1,5 | | 1,5 | 24.11 | | |
| Иҗади диктант | 1,5 | | 1,5 | 1.12 | | |
| Яңа елга багышланган конкурсларга әзерләнү(рәсем,поделка, плакат, сценарий, шигырь...) | 1,5 | | 1,5 | 8.12 | | |
| Район, республика олимпиадасына әзерләнү, катнашу | 1,5 | | 1,5 | 15.12 | | |
| Исемең матур – кемнәр куйган? | 1,5 | | 1,5 | 22.12 | | |
| Авылдаш солдат егетләргә хат язу. | 1,5 | | 1,5 | 29.12 | | |
| “Туган телебезне саклау-һәркемнең изге бурычы”. Иншалар бәйгесе, шигырьләр язу конкурсы. | 1,5 | | 1,5 | 12.01 | | |
| “Тиздән Ватанны саклаучылар бәйрәме” | 1,5 | | 1,5 | 19.01 | | |
| Бирелгән текстның темасын билгеләү, текстка нигезләнеп, соч-ние язуга әзерләнү күнекмәләре. | 1,5 | | 1,5 | 26.01 | | |
| М.Газизов иҗатына күзәтү.,шигырь- җырларын өйрәнү | 1,5 | | 1,5 | 2.02 | | |
| Сурәтләү чаралары (эпитет, метафора, сынландыру). | 1,5 | | 1,5 | 9.02 | | |
| Халыкара туган тел көнен, М.Җәлилне искә алу көнен билгеләп үтү | 1,5 | | 1,5 | 16.02 | | |
| Татар халкының гореф-гадәтләре. | 1,5 | | 1,5 | 23.02 | | |
| Әнием-кадерлем” темасына иҗади эшләр башкару. | 1,5 | | 1,5 | 2.03 | | |
| “Әниләр кичәсе”ннән репортаж әзерләү | 1,5 | | 1,5 | 9.03 | | |
| Туган як тарихы буенча тест. | 1,5 | | 1,5 | 16.03 | | |
| “Минем язучы һәм шагыйрь хезмәтенә мөнәсәбәтем”- әңгәмә | 1,5 | | 1,5 | 23.03 | | |
| Төрле һөнәрләр турында әңгәмә .“Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс” темасына язма эшләр | 1,5 | | 1,5 | 30.03 | | |
| “Бала” сайтына күзәтү ясау | 1,5 | | 1,5 | 6.04 | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| “Исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел!” | 1,5 | | 1,5 | 13.04 | | |
| “Без- Тукайлы халык”**.** Шагыйрь иҗаты буенча “Башваткыч”уены. | 1,5 | | 1,5 | 20.04 | | |
| Тукай туган көненә багышлап “ Шигырь бәйрәме” үткәрү. | 1,5 | | 1,5 | 27.04 | | |
| Туган ягым талантлары. М.Газизов, М.Ханнанова иҗатларына күзәтү. | 1,5 | | 1,5 | 4.05 | | |
| Табигатьне күзәтүләргә нигезләнеп, шигырь язу (синквейн) бәйгесе | 1,5 | | 1,5 | 11.05 | | |
| “Сабантуй”, “Көмеш кыңгырау”, “Заман сулышы” газеталарындагы балалар иҗаты белән танышу. | 1,5 | | 1,5 | 18.05 | | |
| Түгәрәк эшен йомгаклау. Уңыш һәм кимчелекләрне билгеләү. Җәй айларына биремнәр тәкъдим итү. | 1,5 | 1,5 | | 25.05 | | |

**Аттестация/контроль формасы**

Октябрь азагында укучыларның аралашу күнекмәләре тикшерелә. Контроль формасы – тренинг.
Декабрь азагында укучыларның тел белеме, татар әдәбияты буенча белемнәре тикшерелә. Контроль формасы – олимпиада.
Мартта укучыларның туган як тарихы, әдәбияты, мәдәнияты
буенча белемнәре тикшерелә. Контроль формасы – тест.
Майда укучыларның иҗади эшләү күнекмәләре тикшерелә. Контроль формасы – бәйге.

**Әдәбият**


Ганиев Ф.Ә.Хәзерге татар әдәби телендә сүзьясалышы Казан. "Мәгариф" нәшрияты, 2006
Зәкиев М.З Татар синтаксисы Казан. "Мәгариф" нәшрияты, 2005
Максимов. Н.В. Татар теленнән кулланма. Фонетика-Казан: Мәгариф, 2008
Максимов. Н.В. Татар теленнән тестлар: Уку-укыту ярдәмлеге/ -Казан: Мәгариф, 2008
Саттаров Г.Ф. Татар исемнәре сүзлеге. - Казан, 1981. – 255 б,
Саттаров Г.Ф. Исемең матур, кемнәр куйган? – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989.
-256 б.,
"Татарча башваткычлар" электрон газетасы,
Низамов И.М, “Уем тел очында.”-Казан, татар китап нәшрияты
Рәхимов Җәмит. “Шөгер төбәге-хәзинәләр чишмәсе”
“Сабантуй”, “Көмеш кыңгырау”, “Заман сулышы” газеталары, “Ялкын” журналы .